ГЛАВА ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Крупской, д. 6, г. Заинск, 423520

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ
Крупская урамы, 6 йорт, Зәй шәһәре, 423520

Телефон: (85558) 9-90-83 E-mail: zai@tatar.ru сайт: www.zainsk.tatarstan.ru

21.08.2026 № 4709/С

На №_______________ от_________________

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Дүртмунча авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар башлануы турында хәбәр итү**

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Дүртмунча авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проекты (алга таба – проект) буенча гавами тыңлаулар башлануы турында хәбәр итәбез.

**Проектка мәгълүмати материаллар исемлеге:**

1) ШӘҺӘР ТӨЗЕЛЕШЕ РЕГЛАМЕНТЛАРЫ.
2) ШӘҺӘР ТӨЗЕЛЕШЕН ЗОНАЛАШТЫРУ КАРТАСЫ.
3) Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы. Территориаль зоналар.
4) Территорияләрдән файдаланунын махсус шартлары булган зоналар чикләре картасы.
5) ҖИРДӘН ФАЙДАЛАНУ ҺӘМ ТӨЗЕЛЕШ АЛЫП БАРУ КАГЫЙДӘЛӘРЕН КУЛЛАНУ ҺӘМ КҮРСӘТЕЛГӘН КАГЫЙДӘЛӘРГӘ ҮЗГӘРЕШЛӘР КЕРТҮ ТӘРТИБЕ.

**Проект буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе һәм сроклары:**

Ачык тыңлаулар 21.08.2026 елдан 21.09.2026 елга кадәр үткәрелә.

Гавами тыңлаулар үткәрү процедурасына түбәндәге этаплар керә::

гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итү;

проектны һәм аңа мәгълүмати материалларны рәсми сайтта урнаштыру һәм проект экспозицияләрен ачу;

- проект экспозицияләрен үткәрү;
- гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышларын үткәрү;
- гавами тыңлаулар беркетмәсен әзерләү һәм рәсмиләштерү;

гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү һәм бастырып чыгару.

**Гавами тыңлауларда катнашучылар даирәсе:**

- Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Дүртмунча авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче гражданнар;
- Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Дүртмунча авыл җирлеге чикләрендәге җир кишәрлекләренең һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре;

- күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган урыннарның хокук ияләре.

**Гавами тыңлаулар уздырыла торган территория:**

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Дүртмунча авыл җирлеге.

**Гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозицияләрен ачу урыны һәм датасы:**

- 03.09.2026 ел. Дүртмунча авыл җирлеге Башкарма комитеты администрациясе бинасында түбәндәге адрес буенча мәгълүмат стендында: Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Дүртмунча авыл җирлеге, Дүртмунча авылы, Яшьләр ур., 148 йорт;
- 03.09.2026 ел. Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Дүртмунча авыл җирлеге, Дүртмунча авылы, Яшьләр ур., 147 йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында мәгълүмат стендында;
- 03.09.2026 ел. Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Дүртмунча авыл җирлеге, Дүртмунча авылы, Үзәк урам, 95а адресы буенча мәгълүмат стендында;
- 03.09.2026 ел. Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Дүртмунча авыл җирлеге, Кабан-Бастрык авылы, Үзәк урам, 64 адресы буенча мәгълүмат стендында;
- 03.09.2026 ел адресы буенча мәгълүмат стендында: Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Дүртмунча авыл җирлеге, Зичәбаш авылы, Үзәк урам, 36а;
- 03.09.2026 ел. Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты администрациясе бинасында түбәндәге адрес буенча мәгълүмат стендында: Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Зәй шәһәре, Крупская ур., 6 й..

**Проект экспозицияләрен үткәрү сроклары:** 03.09.2026 елдан 10.09.2026 елга кадәр.

**Экспозицияләрне карарга мөмкин булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат:** дүшәмбе-җомга, 08:00 дән 17:00 гә кадәр (МСК).

**Гавами тыңлауларда катнашучыларның проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү тәртибе, сроклары һәм формасы:** 03.09.2026 елдан 10.09.2026 елга кадәр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының (алга таба – РФ ГрК) 5.1 маддәсенең 12 өлеше нигезендә идентификация узган гавами тыңлауларда катнашучылар проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы проект:

- рәсми сайт аша;
- язма рәвештә яисә электрон документ рәвешендә гавами тыңлауларны оештыручы адресына түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Зәй шәһәре, Крупская урамы, 6нчы йорт, каб.12 (дүшәмбе-җомга, 08.00 дән 17.00 гә кадәр);
- Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Дүртмунча авыл җирлеге, Дүртмунча авылы, Яшьләр урамы, 148 йорт (Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Дүртмунча авыл җирлеге башкарма

комитеты администрациясе бинасы) адресы буенча гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясенә килүчеләрне исәпкә алу кенәгәсенә (журналына) язып куюю юлы белән (дүшәмбе-җомга) 08.00 дән 17.00 гә кадәр).

РФ ГрК 5.1 маддәсенең 12 өлеше нигезендә идентификация узган гавами тыңлауларда катнашучылар тыңлауларда катнашучыларның җыелышларын үткәрү барышында язма яисә телдән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы.

**Гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышлары җыелышын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат:**

Проект буенча ачык тыңлаулар 2026 елның 11 сентябрендә узачак:

- Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Дүртмунча авыл җирлеге, Дүртмунча авылы, Яшьләр урамы, 147 йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында 15 сәгать 00 минутта (МСК).

**Гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект урнаштырылачак рәсми сайт турында мәгълүмат һәм аңа мәгълүмати материаллар:**

Зәй муниципаль районының рәсми сайты http://zainsk.tatarstan.ru .

Әлеге хәбәрнамәне Зәй муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

**Зәй муниципаль районы**
**Башлыгы вазифаларын башкаручы** **П.С. Уразайкин**